БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«06» 03 2025 ел

**КАРАР**

№ 106

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 14 августындагы «Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы 665 номерлы карарын (13.09.2024 елгы редакциядә) үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең һәм белгечләренең, житәкчеләрнең гомумтармак вазыйфаларының, сәнгать һәм кинематография, мәдәният хезмәткәрләренең, эшчеләрнең гомумтармак һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәне расларга.

3. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2024 елның 29 июлендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 196 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Балтач муниципаль районының яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнә торган хезмәт хакы, хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләмен саклап калу һәм шул ук квалификациядәге эшләрне башкару шарты белән, әлеге карар нигезендә хезмәт өчен түләү шартларына күчкән вакытка гамәлдә булган хезмәт өчен түләү системасы нигезендә түләнә торган хезмәт хакыннан кимрәк була алмый, дип билгеләргә.

5. Балтач муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары житәкчеләренә, хезмәткәрләрнең тиешле профсоюз органы белән килештереп:

Балтач муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең шартларын билгели торган коллектив шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә;

Балтач муниципаль районының яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә мөһим хезмәт шартларын үзгәртү турында хәбәр итәргә.

6. Әлеге карар 2025 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов